Асия Юнысова

Җәйне сагынам

«Мәгариф» нәшрияты

АСИЯ ЮНЫСОВА

ҖӘЙНЕ САГЫНАМ

Балалар өчен шигырьләр

Рәссамы ***Рөстәм Хәбибуллин***

КАЗАН • «МӘГАРИФ» НӘШРИЯТЫ • 2005

Оныгым Камиләгә багышлыйм.

КОЯШ-РӘССАМ

Кояш иртүк торды да
Алды кулына каләм.
Үзалдына сөйләнде:
«Хәзер нишлисен беләм».

Көнбагышны бер күрүдә
Охшатты ул үзенә.
Сарыга манды чукларын,
Сипкел сипте йөзенә.

Аннан төште су буена,
Яшел каләмен алып.
Яшел күлмәгенә карый
Бака, хәйранга калып.

Тау битендә — җиләклектә
Кояш йөрде тезләнеп,
Каләмнәрен тоткан килеш,
Җиләк-җимеш эзләнеп.

Җиләкләрне берәм-берәм
Буяп чыкты кызылга.
Кызыл матур була инде,
Аңа кем дә кызыга.

Зәңгәр каләм алган иде —
Тирән күлгә тулды су.
Һәйбәт булды ясаганы,
Бик ямьле җәй булды бу!

Яңгырга рәхмәт

Уч төпләрем кабарды,
Чиләк белән су ташып.
Ун чиләк — кыярларга,
Биш чиләк — алмагачка...
Беттем тәмам саташып.

Суган, кишер су көтә,
Туласы бар өч мичкә.
Җиләкләргә — җиде чиләк,
Чәчәкләргә — өч чиләк,
Эшем бетмәстер кичкә.

Хәлем мөшкеллеген күреп,
Әби ярдәмгә килә:
— Теләк ул кабул була,
Ходайдан яңгыр telə.

Суга барам, судан кайтам,
Телдән теләкне әйтәм.
Егәр инде беләккә —
Җиңеләйде көянтәм.

Шул арада бер болыт
(Кайтуы арып-талып)
Ял итәргә уйлады,
Безнең турда тукталып.



Иелеп қарап торды,
Аннан яңгырын койды —
Авыр йөктән арынды.
Тулды минем чиләкләр,
Коендылар җиләкләр.

Ун минутта эш бетте —
Тулды теге өч мичкә.
Ага яздым үзем дә —
Тотынып калдым көчкә.

Ансы гына ярый ла,
Рәхмәт яусын яңгырга.
Миңа эш булган иде,
Ә болытка ял гына.

ТАМЧЫЛАР

Кәеф шәпне каян белә —
Һәр тамчыда кояш көлә!
Көмеш тамчы, бәллүр тамчы,
Иренемә минем тамчы.

Һәр тамчыда тормыш чыңы —
Йотыйм әле бер тамчыны.
Мин генәме? Гөлләр йота,
Тамчы көтә һәр орлык та.

Без үзебез тере тамчы —
Ярышабыз елгырлыкта.
Тамчы юган гөлләрнең дә
Тиңе юк бит матурлыкта.



БАКА ТУЕ

Күл буенда бүген кызык:
Анда уйный оркестр.
Бакылдаган бакаларның
Һәрбересе артисттыр.

Бакаларның туе икән,
Калдым шуны ишетеп.
Туйларына дәшмәгәннәр
Кыз-малайны иш итеп.

Бака туе! Кызык бит, әй!
Күреп калыйк, ашыгыйк.
Соңарганбыз. Ярда ята
Йөзләп бака кашыгы.

Кая булган кияү-кәләш —
Бу хәтлесен кем белә?
Бака туеннан канәгать
Үрдәкләр кайтып килә.

Йөзәргә өйрәнәм

Дулкыннарны коча-коча,
Аякны чапылдатып,
Ике кулны җәеп-җәеп,
Йә суга чалкан ятып
Йөзү рәхәт булыр иде,
Әгәр мин йөзә белсәм.
Әй, йөзәргә өйрәнәм мин,
Бик тә, бик тә теләсәм.

Су буенда хәйран калдым:
Өйрәтүче күп икән!
Йөзә белү мәктәбе дә
Менә шушы күл икән.



— Менә миннән өйрән,— диеп,
Үрдәгем китте ишеп.
Ятьмә тәпиле үрдәккә
Йөзү тора килешеп.

Күл буендагы чыр-чуны
Этем килгән ишетеп.
Акбаемны сайлармындыр
Мин үземә иш итеп.

— Этчә йөзү кыен түгел,—
Менә, дустым, син күр! — ди.
Акбай булгач, батыраеп,
Мин дә суга сикердем.

КАЕН КЫЗЫ

Җиләккә дип барган идем,
Очраттым Каен кызын.
Алан уртасына басып,
Кемне көтә ялгызы?

Үреп салган толымнарын,
Яңа күлмәген кигән.
Җиләкчеләр ял итсенгә,
Күләгәләп иелгән.

— Шәһәр кызы, сиңа,— диде,—
Бар бит әле бүләгем.
Иел генә, син кап кына,
Татлы минем җиләгем.

— Әй арыдым, эсселәдем —
Җиләкчегә көн кызу.
Күләгәңә, бүләгеңә
Мең рәхмәт, Каен кызы!

Җиләк җыям

Алсу җиләк, ал җиләк,
Миңа пешкәне кирәк.
Уңга-сулга каранам,
Табылмый кызыл җиләк.

Алан ямьле. Чәчәкләр
Хуш исен чәчә генә.
Җиләк күрмим, күзем төшә
Кыңгырау чәчәгенә.

Һушым китеп, сокланып,
Табигать хозурына,
Абынып йөрим икән
Җиләкнең кызылына.

— Монда җиләк күп икән...—
Инде җырлыйм такмаклап.
Әниемә дигәннәрен
Җыйдым әле сабаклап.



БӨРЛЕГӘН

Алмагач алсу алмасын
Тәгәрәтә алдыма,
Чия суза чияләрен:
— Аша,— дип,— чат бал гына.

Алма, чия, сливалар
Юмарт, сабыр, юашлар.
Бөрлегәнгә баргач белдем:
Бар ул усал агачлар.

Хәзер усал бөрлегәнгә
Якын килмәм бер дә мин.
Өзгән идем бер җиләген,
Ертты күлмәк итәгеn.

Ахирәт дусты гөлҗимеш
Чәнечкеле — аның иш.
Алай бик усал булгачтын
Кирәкми сезнең җимеш.



АЛКАЛЫ ТӨЛЛӘР

Исем китте чәчәкләргә —
Һәркайсында алка бар.
Күлмәкләре төсендәдер —
Зәңгәре дә, ал да бар.

Алкаларны чәчәкләргә
Бүләк иткән Таң кызы.
Чәчәкләрдә күрәм икән
Таң кызының йолдызын.

Йолдыз алка — бер могҗиза,
Һәркайсында дөнья бар.
Чык тамчысы — нурлы күздә
Хәтта син дә, мин дә бар.

Чәчәкләргә бик кызыктым,
Мин дә алка алдырдым.
Тамчы алка киеп куеп,
Барсын хәйран калдырдым.

Кояш күргәч, алкаларын
Гөлләр төшерде кагып,
Ә мин менә алкаларым
Йөрим көн буе тагып.

КҮБӘЛӘК БЕЛӘН МИН

Әй күбәләк, дустым бул,
Гөлгә кунма, миңа кун.
Очып аргач, ял итәргә
Иң җайлысы минем кул.

Син — күбәләк, мин — нәни,
Аерылмыйбыз әллә ни.
Синекенә охшатып,
Күлмәгем текте әни.

Чәчәктән чәчәккә чүгәм,
Мин үзем дә сиңа тиң.
Синекедәй канатым ул —
Күлмәктә күбәләк җиң.

Чәчемдәге тасмаларым
Бәйләнгән күбәләкләп,
Игез күбәләк кебек
Уйныйк, әйдә, икәүләп.

Арышлар арасында

Качтым әле барыгыздан
Арышлар арасына.
Кара күзле күкчәчәкне
Бер эзләп карасыннар.

Арышлар биек үскәнме
Мине яшерер өчен,
Алтын башаклары белән
Төшемә керер өчен?

Монда бик әйбәт булса да
Уйнар өчен качышлы,
Арыш ипие өчен дип
Үстерәләр арышны.

Арыш ипиен ашауга
Үсәрмен карыш буе.
Бу җәйдә үк сузылырмын
Мин качкан арыш буе.

Ул чагында, ул чагында...
Монда бүтән качалмам.
Үземне дә күрдең инде,
Чакыр инде: «Чык, алмам!»

КАРГАДАН САБАК

Берәү, икәү, өчәү, дүртәү...
Унөч бәбкә санадым.
Чирәмлектә мин аларны
Каргалардан сакладым.

Сары йомшак йомгакларым
Бәбкә үләне йолка.
Карга заты да күренми,
Әллә куркам гел юкка.

Бәбкәләрем, шаярышып,
Бер-берсен куып уйный.
Мин дә бераз уйнап килсәм,
Берни булмас дип уйлыйм.

Берәү, икәү, өчәү, дүртәү...
Унике генә калган.
Унөченче бәбкә кая,
Карак каргамы алган?

Мин бәбкәләр саклаганда,
Карга мине караган.
Гамьсез булганым өчен,
Сабак алдым каргадан.



Сикергеч

Сикергечем тиз йөртә,
Сикертә дә сикертә.
Миңа кызыга әнә
Озынаяк чикерткә.

Сикерәм мин, сикерәм;
Саныйм — җиткерәм йөзгә.
Йә, кайсыгыз иярә
Минем кебек җитезгә?

Очып-очып сикерәм,
Ике кулым — канатым.
Кирәк җиргә тиз өлгерәм,
Сикергеч — минем атым.

Атлый-сикерә генә
Төшеп мендем чишмәгә,
Сикергечнең хәле бетәр,
Чишмә суын эчмәгәч.

ТУП

Тупыл-тупыл тупылдый,
Бер урында тик тормый.
Оста биюче кебек,
Тыпыр-тыпыр тыпырдый.

Бармак очы тиюгә
Әллә кая сикерә.
Тотып алам дигәндә
Миннән качып өлгерә.

Тик торганда тәгәри,
— Калма, арттан йөгер,— ди.—
Суга төшәм, чыланам,
Мине тотып өлгер,— ди.

Әле генә учта иде,
Инде очты югары.
Ничек шулай булдыра,
Юк аягы, юк кулы?

Зәңгелә*, кач!

Кышлар үтеп, яз булгач,
Кузгалак җыеп кайткач,
Дога әйтте әбием:
— Идел кич тә, зәңгелә, кач,
Иске авызга яңа аш!

Инде әни пешергәч,
Кычыткannan тәмле аш,
Тагын әйтте әбием:
— Идел кич тә, зәңгелә, кач,
Иске авызга яңа аш!

Әбекәйнең догасы
Ошап китте бит безгә.
— Идел кич,— дия-дия,—
Зәңгелә, кач! — дия-дия,
Килеп кердек без көзгә.

Җиләк, чия, бөрлегән,
Балан, шомырт, карлыган...
Бер җимеш тә калмаган,
Без кабып карамаган.

Яңа аш кабар өчен,
Без гел авызны ачтык.
Идел кичтекме— юкмы,
Зәңгелә бездән качты.

---

* *Зәңгелә* — чир, витаминнар, бигрәк тә «С» витамины җитмәгәндә була.

Җәйне сагынам

Бүген торсам соң гына,
Каеннарның яфрагын,
Сыңар-сыңарын гына,
Кем буяган сарыга?

Көз ул йөргән. Ашыккан.
Буяр иде соңыннан.
Җәй үтеп тә бетмәгән,
Ә мин аны сагынам.

ЯҢА ТУФЛИЛӘР

— Абау матур! Алыйк, алыйк
Менә бу туфлиләрне!
Алмый китсәк үкенербез,
Алмый киту — юләрлек.

Мин теләгән туфлиләр бу,
Шундый җайлы табаны.
Бер кибеттән табалмабыз
Болар кебек таманны.

Шулай телгә остардым мин,
Әниемне кыстадым.
Биеп тә күрсәттем әле,
Сиздермәдем кысканын.

Өйгә кадәр киеп кайттым,
Әле ничек түзгәнмен?
Адым саен сизеп тордым
Аягымның үскәнен.

Юкка мактадым бугай ла
Туфлине баягынак.
Салып аттым үзләрен,
Йөгердем яланаяк.





Сәгать

Сәгать иртә уяна,
Аннан мине уята.
Ә мин йокы яратам,
Уянгач тормый ятам.

Бүген сәгать туктаган,
Уятып та тормаган.
Үзе миннән курмәкче
Кырын ятып йоклаган.

МИН УҢГАН КЫЗ

Чигү чигәм

Чигү чиккән җитү кызлар,
Ә мин әле бәләкәй.
Үзем бәләкәй булсам да,
Шактый гына хәйләкәр.

Әни өйдә юк чагында
Чигү чигәм яшереп.
Чигү чигәм ак җирлеккә,
Ал җиләкләр төшереп.

Әнинең туган көненә
Шушы булыр бүләгем.
Әниемне сөендерер
Минем алсу җиләгем.



Бәйлим дә әле

Бик тиз оттым бәйләү җаен,
Бер чалам да, бер эләм.
Кулларыма күз иярми,
Биеп тора биш энәм.

Башлык бәйлим, оек бәйлим,
Бәйлим әле күлмәкләр.
Җеп йомгагын кием итә
«Күзләр» дигән элмәкләр.

Бәйләм «күзе» — көннәр алар,
Күлмәк гомер кебекме?
Матур бәйләп кияр идем
Гомер дигән күлмәкне.

Челтәр үрәм

— Оста кулдан кәтүк җебе
Чыга,— ди,— челтәрләнеп.
Челтәр бәйләгән чагында
Китәсең чибәрләнеп.—

Шулай ди миңа әбием,
Гамәлемне яратып.
Челтәр япмага сибәм мин
Чәчәкләрне таратып.

— Кул эшенә маһир кызлар
Мактаулы һәр чорда да.
Мондый кызым барында,— ди,—
Каба төшәр чормадан.



КЕМ ОСТА?

Рәсемнәргә зур конкурс
Булды безнең сыйныфта.
Йә, кайсыбыз шәбрәк ясый,
Йә, кайсыбыз иң оста?!

— Тыныч кына утыр,— диеп,
Әйтеп куйдым песигә.
Битен юган песиемне
Төшердем мин рәсемгә.

Сурәтем бик әйбәт чыкты,
Гаҗәп түгел — тырыштым!
Сеңлем җиңеп чыксын, диеп,
Апам да бик булышты.

Мин түгел шул, Рәсим җиңде
Бу ярыш-конкурста.
Аның абыйсы, күрәсең,
Минем апамнан оста.

СИХЕРЧЕ

Ә мин менә күп төрле
Тылсым серләре беләм.
Әбиемә мактанмакчы
Шушы гыйлемем белән:

— Әйдә, чыгабыз урамга,
Кодрәтемне күрсәтим,
Кулым изәп җил чакырыйм,
Агачларны селкетим.

— Болай да җилле урамда,
Агачлар да селкенә.
Әбиеңнең яшьлеген, вәт,
Табып китер син менә!

Мондый катлаулы йомышка
Чынлап торып үпкәлим.
Без бит «Тылсым» мәктәбендә
Яшьлек серен үтмәдек.



МОҢЛЫ ПЕСИ

Ноталарга карый-карый
Пианинода уйныйм.
Җырлый белгән моңлы песи
Мин генәдер дип уйлыйм.

Клавишлардан йөгереп үтеп,
Аккорд алам мин шулай.
Түбә кыегы көйләрен
Өйдә уйныйм шушылай.

Талантлы да, матур да мин —
Даным китте еракка!
Гашыйк песиләрем миңа
Карап тора ярыктан.

Икебезгә бер җыр

Ул миңа сырпалана,
Мин аңа сырпаланам.
Иркәлисем килгәндә,
Пескәйне кулга алам.

Йомшак йонлы гармуным —
Сыры саен мыр гына.
Мин дә кушылып җырлыйм
Пескәемнең җырына.

НОТАЛАР

Карап торуга ук кызык
Нота язылган сызык.
Сызык түгел, чыбыклар.
Нота булып уйный икән
Өтер кебек чыпчыклар.

Йә, ничекләр уеныгыз,
Уйный соң ничәвегез?
Сикермәгез, чүгегез!
Берәү, икәү... сигез икән.
Җитәдер җидәвегез.

Нота — җиде, сез — сигез.
Саныгыз түгел тигез.
Йә, кайсыгыз «до», «ре», «ми»?
Әллә токтан, әллә юктан
Тимерчыбык дерелди.

Җиде чыпчык, җиде нота —
До-ре-ми-фа-соль-ля-си!
Инде җырлыйк берәр җыр.
Сигезенче — иң җитезе!
Син булырсың дирижёр.



ЭЧТӘЛЕК

Кояш-рәссам 2
Яңгырга рәхмәт 4
Тамчылар 6
Бака туе 7
Йөзәргә өйрәнәм 8
Каен кызы 10
Җиләк җыям 11
Бөрлегән 12
Алкалы гөлләр 13
Күбәләк белән мин 14
Арышлар арасында 15
Каргадан сабак 16
Сикергеч 17
Туп 18
Зәңгелә, кач! 19
Җәйне сагынам 20
Яңа туфлиләр 21
Сәгать 22
Мин уңган кыз 23
Чигү чигәм 23
Бәйлим дә әле 24
Челтәр үрәм 25
Кем оста? 26
Сихерче 27
Моңлы песи 28
Икебезгә бер җыр 29
Ноталар 30

УДК 821.512.145-1-93
ББК 84(2Рос = Тат)-5
Ю61

Юнысова А. Ш.

Ю61 Җәйне сагынам: Балалар өчен шигырьләр / Асия Юнысова.—Казан: Мәгариф, 2005.— 31 б.: рәс. б-н.

ISBN 5-7761-1525-6

Литературно-художественное издание
Для младшего школьного возраста

Юнусова Асия Шайхразиевна

ГДЕ ТЫ, ЛЕТО?

Стихи для детей

Казань. Издательство «Магариф». 2005
На татарском языке

Әдәби-нәфис басма
Кече яшьтәге мәктәп балалары өчен

Юнысова Асия Шәйхразиевна

ҖӘЙНЕ САГЫНАМ

Балалар өчен шигырьләр

Редакторы *В. Г. Гомәрова*
Бизәлеш редакторы *Л. С. Золондинова*
Техник редакторы һәм компьютерда биткә салучысы *М. И. Данилевская*
Корректоры *Г. Р. Ногманова*
Рәсемнәрне компьютерда эшкәртүчесе *Л. Р. Вафина*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 05.10.05.
Форматы 60×90 $^1/_8$. Офсет кәгазе. «Школьная» гарнитурасы.
Офсет басма. Басма табагы 4,0. Нәшер-хисап табагы 6,7.
Тиражы 3000 д. Заказ А-724.

«Мәгариф» нәшрияты. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
Тел./факс (843) 292-57-48.
http: // magarif. kazan. ru
E-mail: magarif @ mail. ru

ААҖ ПИК «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.

ISBN 5-7761-1525-6

© «Мәгариф» нәшрияты, 2005
© Бизәү. «Мәгариф» нәшрияты, 2005